Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы

Бәзәкә авыл җирлеге составына керүче

Бәзәкә авылында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

24 ноябрь 2023 ел № 2

2024 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә

1.Бәзәкә авылында насос сатып алу

2.Янгын сүндерү машинасы өчен янгын сүндерү җиһазлары, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу.

3. Бәзәкә авылындагы юлларны кардан чистарту.

4. Бәзәкә авылына вак таш сатып алу, ташу, тигезләү.

5. Бәзәкә авылында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр.

6. Бәзәкә авылында үлән чабу буенча хезмәтләр.

7. Бәзәкә авылында яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру.

8. Чишмәне ремонтлау, Бәзәкә авылындагы чишмане ремонтлау,чишма янын территориясен төзекләндерү

9. Бәзәкә авылында "Үлемсез полк" стендын ясау

10 Бәзәкә авылына керү урынында Стелла урнаштыру

11. Бәзәкә авылында чара үткәрү өчен аппаратура сатып алу.

12. Бәзәкә авылында белдерүләр тактасы урнаштыру.

13. Кар җыю машинасы сатып алу.

14. Бәзәкә авылындагы күперне буяу өчен буяу сатып алу.

15. Балалар спорт мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру, балалар спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов